Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының илле беренче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

26 февраль, 2025 ел № 384

1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераны Макаров Алексей Петровичка «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирү турында

Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин йөкләмәсен үтәү йөзеннән һәм 1941 - 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру кысаларында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирү турындагы үтенечнамәсен карап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар карар кабул итте:**

1. 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераны Макаров Алексей Петровичка «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирергә.
2. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Р.Вәлиуллинга йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов